ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРСАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул .Центральная, д.5, с. Урсаево,
Заинский район, 423535

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРСАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Центральная урамы, 5 нче йорт,
Урсай авылы, Зәй районы, 423535

Телефон, факс 2-80-46.
Электронный адрес: Ursaev.zai@tatar.ru, сайт: http://zainsk.tatarstan.ru/rus/ursaevskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.02.2026 г.** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, « түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2026 елның 23 январендагы 30 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. 2026 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9678,63 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” 2025 елның 31 январендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип таныргга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Н.Ә. Гатина

Зәй муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге
башкарма комитетының
«03» февральдә 2026ел
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән
Урсай авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3681,24 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1573,46 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4423,93 |
| Барысы | 9678,63 |

Зәй муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге
башкарма комитетының
«03» февральдә 2026ел
2номерлы карарына
2 нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән
Урсай авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 1009,41 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2747,27 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1535,83 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4386,12 |
| Барысы | 9678,63 |